**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.07.2017 № 01-02/75

г. Казань

Татарстан Республикасы Зеленодольск районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннар исемлегенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы Зеленодольск районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/75 номерлы боерыгы белән расланган исемлеген тулыландыру турындагы тәкъдимен исәпкә алып, **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/75 номерлы боерыгы белән расланган исемлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «1 | Зеленодольск шәһәре | Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһәре, Ленин ур., 13 йорт | Ленин урамы буенча «Родина» мәдәният сарае янындагы 13 нче йорт территориясе |
| | | Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 62 йорт | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 62 йорт адресы буенча урнашкан «Метеор» спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль автоном учреждениесенә орынып торучы мәйдан |

2. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә (А.Г.Сафин) әлеге боерыкны "Татарстан Республикасының рәсми порталы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегенә (Э.И.Слепнева) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтовка йөкләргә.

Министр Р.И.Заһидуллин

Килештерүчеләр:

Татарстан Республикасы
юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтов

Норматив хокукый актларны теркәү
һәм Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгы эшчәнлеген
хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы Э.И.Слепнева

Җирле үзидарә органнарына
хокукый консультацион-методик
ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы М.А.Пашкова

Боерыкны әзерләде:
Җирле үзидарә органнарына хокукый
консультацион-методик ярдәм күрсәтү
бүлегенең әйдәп баручы советнигы А.Н.Ханеня